Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Ивановка авыл җирлегенең Ивановка торак пункты гражданнар җыены
КАРАРЫ

2024 елның 1 апреле № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановкаавыл җирлегенең Ивановка торак пунктында гражданнар Җыенының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Ивановка торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында»2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы (29.11.2023 №1532 редакциясендә) карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән,Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, 2024 елның 1 апрелендәге «Сез 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Ивановка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карары һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Ивановка торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарына үзгәреш кертү турында 2024 елның 1 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Ивановка торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Ивановкаторак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы һәм «Ивановка авыл җирлегенең Ивановка торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

а) преамбулада һәм 19.11.2023 ел, №1 карарның 2 пунктында һәм 19.11.2023 ел, №2 карарның 1 пунктында «I төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән хәрби хезмәткәрләрдән, күп балалы гаиләләрдән тыш» сүзләрен «I һәм II төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән хәрби хезмәткәрләрдән, контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрдән, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, күп балалы гаиләләрдән тыш" сүзләренә алыштырырга;

б) алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Ивановка авылында Нагорная урамы, Яшьлек урамы, Заречная урамы, Мәктәп тыкрыгы буенча вак таш юлларны чокырлы ремонтлау; Ивановка авылында юлларны кардан чистарту (Үзәк, октябрь, яшьлек, Заречная, Нагорная, Энтузиастлар, Чишмә, Мәктәп тыкрыгы));

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Ивановка авылы территориясендә үлән чабу; бензокос (триммер) сатып алу; триммер өчен ягулык-

майлау материаллары сатып алу);

3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу; янгын сүндерү җиһазлары һәм янгын сүндерү инвентаре сатып алу; янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Ивановка авылы, Яшьлек урамы, 5, Аккүл авылы,Колхоз урамы, 16Б; Медведка авылы, Юл урамы, 32; Михайловка авылы, Үзәк урам, 4 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П.Бодряева